**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3967**
**16.05.2023**

Башкарма комитетның 2021 елның 1 июлендәге 4423 номерлы карары белән расланган муниципаль милектәге җирләрне һәм (яки) җир участокларын һәм шәхси милектәге җир участокларын яңадан бүлү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль законның 3.5 статьясының 10 пункты, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2021 елның 1 июлендәге 4423 номерлы карары (Башкарма комитетның 2022 елның 7 октябрендәге 5359 номерлы карары редакциясендә) белән расланган муниципаль милектәге җирләрне һәм (яки) җир участокларын һәм шәхси милектәге җир участокларын яңадан бүлү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.5.1. пунктның 4 пунктчасында «Россия Икътисадый үсеш министрлыгының «Җир участогын яки җир участокларын территориянең кадастр планында урнаштыру схемасын әзерләүгә һәм, җир участогын яки җир участокларын территориянең кадастр планында урнаштыру схемасын электрон документ формасында әзерләгәндә, җир участогын яки җир

участокларын территориянең кадастр планында урнаштыру схемасы форматына карата таләпләрне һәм аны әзерләү кәгазь документ формасында гамәлгә ашырыла торган җир участогын яки җир участокларын территориянең кадастр планында урнаштыру схемасы формасын раслау турында» 2014 елның 27 ноябрендәге 762 номерлы боерыгында каралган башка форматларда» сүзләрен «Росреестрның 2022 елның 19 апрелендәге П/0148 номерлы Боерыгы белән расланган формада» сүзләренә алмаштырырга;

2) 2.6.1 пунктта 5, 7, 8 пунктчалар үз көчен югалткан дип танырга;

3) түбәндәге эчтәлектәге 3.8 пункт өстәргә:

«3.8. Гомуми билгеләре буенча, шул исәптән аны алу өчен мөрәҗәгать иткән муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә мөнәсәбәтле рәвештә берләштерелгән гариза бирүчеләрнең аерым категорияләренә муниципаль хезмәт күрсәтү.

Муниципаль хезмәт гариза бирүченең категориясенә һәм мөрәҗәгатьнең нигезенә бәйсез рәвештә күрсәтелә.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов